| **closing chevron** | закрывающая парная кавычка | яба торган почмаклы куштырнак |
| **closing parenthesis** | закрывающая круглая скобка | яба торган түгәрәк җәя |
| **cloud** | облако, туча | болыт |
| **cloudy** | облачно | болытлы |
| **cluster** | **I** *сущ.* кластер (1. многомашинная вычислительная система 2. группа секторов на жёстком диске) **II** *гл.* объединить в кластер, объединить в группу, объединить в блок | **I** *и.* 1. кластер (күп җайланмалы исәпләү системасы 2. кластер (каты дискта бер төркем бүлек) **II** *ф.* кластерга / төркемгә / блокка берләштерү |
| **CMOS memory** | CMOS-память | CMOS хәтер (микросхема тур.) |
| **coaxial** | коаксиальный, совпадающий осями, имеющий общую ось | күчәрдәш, коаксиаль |
| **coaxial cable** | коаксиальный кабель | коаксиаль кабель (компьютерларда кулланыла торган төп өч төр кабельнең берсе) |

| | | |
|---|---|---|
| **code** | I *сущ.* 1. код [программы] 2. система кодирования 3. стандарт II *гл.* кодировать, шифровать | I *и.* 1. код (программада командаларның аерым бер эзлекле тәртибе) 2. кодлау системасы 3. стандарт II *ф.* кодлау, шифрлау |
| **code generator** | 1. генератор приложений 2. кодогенератор, генератор кода | 1. кушымталар генераторы (мәгълүмат базасын файдалануда кирәкле кушымта программалар төзү өчен кулланыла) 2. кодогенератор, код генераторы (программалаштыру теле тур.) |
| **code of conduct** | правила поведения | кагыйдәләр, тәртип кагыйдәләре |
| **code page** | кодовая страница | кодлар бите |
| **codec** | кодек | кодек |
| **coder** | кодер, кодирующее устройство | кодер, кодлау җайланмасы |
| **coding** | кодирование | кодлау |
| **coding tricks** | трюки кодирования [программ] | [программаларны] кодлау серләре |
| **collapse** | свернуть | [файл, текст һ. б. ш.] җыю, ябу, төреп кую |
| **collate** | объединить | берләштерү |

| | | |
|---|---|---|
| **colleague** | коллега | хезмәттәш, коллега |
| **collision** | столкновение, конфликт, коллизия | бәрелеш, конфликт, коллизия |
| **color** | цвет | төс |
| **color blending** | смешивание цветов | төсләрне катнаштыру, төсләрне кушу |
| **color box** | палитра | палитра |
| **color gamut** | цветовая палитра | төсләр палитрасы |
| **color marker** | цветовой маркер | төсле маркер |
| **color model** | цветовая модель | төс моделе |
| **color monitor** | цветной монитор | төсле монитор |
| **color palette** | цветовая палитра | төс палитрасы |
| **color printer** | цветной принтер | төсле принтер |
| **color profile** | цветовой профиль | төс профиле |
| **color saturation** | насыщенность цвета | төс куелыгы |
| **color scheme** | цветовая схема | төсләр схемасы |
| **color separation** | цветоделение | төсләр бүленеше, төсләрне бүлү |
| **color space model** | цветовое пространство | җыелма төс ясау моделе |

| | | |
|---|---|---|
| **color temperature** | цветовая температура | төс температурасы |
| **column** | столбец, колонка | багана |
| **column break** | разрыв столбца | багана ахыры |
| **column chart** | гистограмма | гистограмма, баганалы диаграмма |
| **column heading** | заголовок столбца | багана исеме |
| **column selector** | знак выбора всех столбцов | барлык баганаларны сайлау билгесе |
| **COM port** | *см.* **communications port** | |
| **combo box** | поле со списком | катнаш күз |
| **comma** | запятая | өтер |
| **command** | команда | команда |
| **command bar** | линейка команд | командалар линейкасы |
| **command file** | командный файл, пакетный файл | команда файлы, пакет файлы |
| **command line** | командная строка | команда юлы |
| **command mode** | командный режим | команда режимы |
| **command processor** | командный процессор, процессор командного языка | команда процессоры, команда теле процессоры |

| | | |
|---|---|---|
| **comment** | I *сущ.* комментарий II *гл.* комментировать | I *и.* комментарий, аңлатма II *ф.* аңлатма бирү, шәрехләү |
| **commercial product** | изделие невоенного назначения | коммерция продукты |
| **communications port** | коммуникационный порт, COM-порт | коммуникацион порт, COM-порт (модем, принтер һ. б. ш. компьютерга тоташтыру урыны) |
| **community** | сообщество | берләшмә |
| **compact disc-recordable** | компакт-диск для однократной записи | бер кат яздырып укыла торган компакт диск |
| **compact disc-rewritable** | перезаписываемый компакт-диск | кат-кат яздырып укыла торган компакт диск |
| **company** | компания | компания, ширкәт |
| **compare** | сравнить | чагыштыру |
| **comparison operation** | операция отношения, операция сравнения | чагыштыру гамәле |
| **compatibility** | совместимость | ярашу, ярашлылык |
| **compatibility checker** | средство проверки совместимости | ярашуны тикшергеч, ярашуны сынагыч |
| **compatibility mode** | режим совместимости | ярашу режимы |
| **compatibility testing** | тестирование на совместимость | ярашуны сынау |

| | | |
|---|---|---|
| **compatible** | совместимый | ярашлы, яраша торган |
| **compilation** | компиляция, трансляция | компиляциялəү, [үзгəртеп] күчерү (төзелгəн программаны бер программалаштыру теленнəн икенчесенə, ягъни машина теленə яки шуңа якын кодлы арадаш телгə күчерү) |
| **compilation time** | время компиляции | компиляциялəү вакыты (төзелгəн программаны бер телдəн икенчесенə, ягъни машина теленə яки шуңа якын кодлы арадаш телгə күчерү вакыты) |
| **compile** | компилировать | компиляциялəү |
| **compiler** | компилятор, транслятор программы | компилятор, үзгəртеп күчергеч [программа] |
| **complement** | дополнение | өстəмə |
| **complementary colors** | дополняющие цвета | өстəмə төслəр |
| **complete** | **I** *прил.* полный, законченный, завершённый **II** *гл.* завершить | **I** *с.* тулы, тəмамланган **II** *ф.* тəмамлау |
| **completed** | завершено | тəмам |
| **completion code** | код завершения | тəмамлау коды (кайбер гамəл яки программа эшлəүдəн туктаганда чыга торган сан) |

| | | |
|---|---|---|
| **complex script** | набор сложных знаков | катлаулы символлар җыелмасы |
| **component** | компонент | компонент |
| **compose** | создать | төзү, булдыру |
| **composite character** | составной знак | катнаш символ |
| **composite map** | комбинированная карта | катнаш карта (төрле эчтәлектәге берничә тематик карта мәгълүматын берләштергән электрон карта) |
| **composite video** | полный (составной) видеосигнал | катлаулы видеосигнал |
| **compound document** | составной документ | кушма документ |
| **compound key** | составной ключ | катлаулы ачкыч |
| **compound statement** | составной оператор | кушма оператор, логик блок |
| **compress** | сжать | кысу, тыгызлау |
| **compressed audio** | сжатый аудиосигнал | кысылган аудиосигнал |
| **compressed disk** | сжатый диск | кысылган диск |
| **compressed video** | сжатое видеоизображение | кысылган видеосурәт |
| **compression** | сжатие | кысу, тыгызлау |

| | | |
|---|---|---|
| **computational complexity** | вычислительная сложность | исәпләү катлаулылыгы |
| **computer** | компьютер, электронная вычислительная машина, ЭВМ | компьютер, санак, электрон исәпләү машинасы, ЭВМ |
| **computer administrator** | администратор компьютера | компьютер администраторы |
| **computer architecture** | архитектура ЭВМ | компьютер архитектурасы |
| **computer club** | компьютерный клуб | компьютер клубы |
| **computer communication** | компьютерная связь | компьютер элемтәсе |
| **computer conference** | телеконференция | телеконференция |
| **computer graphics** | компьютерная графика, машинная графика | компьютер графикасы, машина графикасы |
| **computer hardware** | технические средства компьютера | компьютер җиһазлары |
| **computer language** | машинный язык | машина теле, компьютер теле |
| **computer literacy** | компьютерная грамотность | компьютер грамоталылыгы |
| **computer name** | сетевое имя персонального компьютера (ПК) | компьютер исеме |

| | | |
|---|---|---|
| **computer network** | сеть ЭВМ, вычислительная сеть, компьютерная сеть | компьютер челтәре |
| **computer operation** | машинная операция | машина гамәле, компьютер гамәле |
| **computer performance** | производительность компьютера, производительность ЭВМ | компьютерның эшләү тизлеге, компьютерның нәтиҗәлелеге |
| **computer platform** | компьютерная платформа, платформа | компьютер платформасы, платформа |
| **computer program** | компьютерная программа | компьютер программасы |
| **computer software** | программное обеспечение ЭВМ | компьютер программа тәэминаты |
| **computer system** | вычислительная система | исәпләү системасы, компьютер системасы |
| **computer system architecture** | архитектура вычислительной системы | исәпләү системасы архитектурасы, компьютер системасы төзелеше |
| **computer time** | машинное время | машина вакыты, компьютер вакыты |
| **computer trespasser** | *см.* **hacker** | |
| **computer virus** | компьютерный вирус, вирус | компьютер вирусы, вирус |

| | | |
|---|---|---|
| **computer-aided design (CAD)** | автоматизированное проектирование, система автоматизированного проектирования (САПР) | автоматлаштырылган проектлау, автоматлаштырылган проектлау системасы |
| **Computer-Aided Software Engineering (CASE)** | система автоматизированной разработки программ, CASE-технология | автоматлаштырылган программа төзү системасы, CASE технологиясе |
| **computer-based training (CBT)** | автоматизированная подготовка | автоматлаштырылган өйрәтү системасы |
| **computer-generated imagery (CGI)** | компьютерная анимация, компьютерный видеоряд | компьютер анимациясе, компьютер видеорәте |
| **computing partition** | вычислительное разбиение | исәпләү нигезендә бүлү |
| **concatenation** | конкатенация, сцепление | конкатенация, эзлекле ялгау, тезү, берләштерү |
| **concentrator** | концентратор, хаб | концентратор, хаб |
| **concordance file** | файл словаря предметного указателя | конкорданс файлы |
| **condition** | условие | шарт |
| **conditional** | условный | шартлы |

| | | |
|---|---|---|
| **conditional compilation** | условная компиляция | шартлы компиляция |
| **conditional expression** | условное выражение | шартлы аңлатма |
| **conditional formatting** | условное форматирование | шартлы форматлау |
| **conditional statement** | условный оператор | шартлы оператор |
| **conditionally** | условно, при выполнении условий | шартлы |
| **conference** | конференция | конференция |
| **configuration** | конфигурация, настройка | конфигурация |
| **configuration file** | файл конфигурации | конфигурация файлы |
| **configuration set** | набор конфигурации | көйләү мөмкинлекләре, конфигурация җыелмасы |
| **configure** | настроить | көйләү |
| **confirm** | подтвердить, утвердить | раслау |
| **conflict** | конфликт | конфликт |
| **conflict situation** | конфликтная ситуация, конфликт | конфликтлы ситуация, конфликтлы хәл, конфликт, каршылыклы хәл |

| | | |
|---|---|---|
| **confused** | озадаченный | аптырашлы, аптыраган |
| **connect** | соединить, подключить | тоташтыру |
| **connect time** | продолжительность сеанса связи | элемтә дәвамлылыгы |
| **connected** | подключено | тоташкан |
| **connected standby** | подключенный режим ожидания | тоташып көтү режимы |
| **connection** | соединение, подключение; связь | тоташу; элемтә |
| **connectivity** | возможность подключения | тоташу мөмкинлеге |
| **connector** | разъём | оя, коннектор |
| **consistent** | единообразный | эзлекле, бердәйләштерелгән (бердәй программалаштыру теле, техник чаралар һ. б. ш. тур.) |
| **console** | консоль | консоль |
| **consolidated database** | консолидированная БД | берләштерелгән мәгълүмат базасы |
| **constant** | константа, постоянная величина | константа |
| **contact** | контакт | контакт (кеше тур.) |
| **contact group** | группа контактов | контактлар төркеме |

| | | |
|---|---|---|
| **contact index** | указатель контактов | контактлар индексы |
| **contact-management** | управление деловыми контактами | контактлар белән идарә итү |
| **container** | контейнер | контейнер |
| **content** | содержимое | контент, эчтәлек (аудио-, видеофайллар, рәсем, текст һ. б. шәкелдә мәгълүмат) |
| **content analysis** | контент-анализ | контент анализлау |
| **content library** | библиотека содержимого, библиотека контента | контент тупланмасы, эчтәлекнамә |
| **content provider (CP)** | провайдер контента | контент провайдеры |
| **content rating** | оценка содержимого | контентны бәяләү, эчтәлекне бәяләү |
| **content template** | шаблон содержимого | эчтәлек шаблоны |
| **content type** | тип контента | эчтәлек тибы |
| **content virus** | вирус информационного наполнения, контентный вирус | контент вирусы |
| **context menu** | контекстное меню | контекст менюы |
| **context-sensitive** | контекстно-чувствительный | контекстка сизгер, контекстка бәйле |

| | | |
|---|---|---|
| **context-sensitive help** | контекстно-зависимая справка | контекстка бәйле белешмә |
| **contiguous** | смежный, последовательный, непрерывный (о блоках памяти) | чиктәш, янәшә, бер-бер артлы (хәтер блоклары тур.) |
| **contingency** | непредвиденная ситуация, аварийная ситуация | көтелмәгән хәл, гадәттән тыш хәл |
| **continue** | продолжить | дәвам итү |
| **continuous** | непрерывный | туктаусыз |
| **contrast** | контрастность | контрастлык (монитордагы ачык һәм тонык төсләрнең үзара нисбәте тур.) |
| **contributor** | участник (внёсший вклад) | катнашучы, өлеш кертүче |
| **control** | 1. управление 2. элемент управления | 1. идарә 2. идарә элементы |
| **control key** | управляющая клавиша | идарә төймәсе |
| **control panel** | панель управления | идарә панеле |
| **control signal** | управляющий сигнал | идарә сигналы |
| **control statement** | управляющий оператор | идарә операторы |
| **control transfer** | передача управления | идарәне тапшыру |

| | | |
|---|---|---|
| **control unit (CU)** | устройство управления | идарә җайланмасы |
| **controller** | контроллер | контроллер |
| **conversation** | беседа, диалог; обмен сообщениями | әңгәмә; язышу |
| **conversational processor** | диалоговый процессор | диалог процессоры |
| **conversion** | 1. преобразование 2. перекодировка | 1. үзгәртү, ...га әйләндерү (программалаштыру телендә мәгълүматны бер рәвештән икенче рәвешкә автомат үзгәртү) 2. яңадан кодлау |
| **conversion table** | таблица преобразований, таблица перекодировки | ...га үзгәртү таблицасы, кодларны үзгәртү таблицасы |
| **convert** | преобразовать, конвертировать | ...га үзгәртү, конвертацияләү |
| **converter** | преобразователь | конвертер, сигнал үзгәрткеч (программа, җайланма тур.) |
| **cookie** | файл «cookie», куки | «cookie» файлы, куки файл (сайтка кабат кергәндә, кулланучыны таныклау өчен кирәкле мәгълүмат) |
| **cooler** | кулер | кулер |

| | | |
|---|---|---|
| **coordinate** | координата | координат |
| **coordinate pair** | пара координат | координатлар пары |
| **coprocessor** | сопроцессор | өстәмә процессор |
| **copy** | **I** *сущ.* 1. копия 2. образец<br>**II** *гл.* 1. снимать копию, копировать 2. брать за образец | **I** *и.* 1. күчермә, нөсхә 2. үрнәк<br>**II** *ф.* 1. күчермәсен алу, нөсхәсен булдыру 2. үрнәк итеп алу |
| **copyright** | авторское право | авторлык хокукы |
| **copyright sign** | знак авторского права (©) | авторлык хокукы билгесе (©) |
| **copyright symbol (©)** | *см.* **copyright sign** | |
| **cordless mouse** | беспроводная мышь | чыбыксыз тычкан |
| **core** | 1. оперативная память 2. ядро 3. стержень; медная жила (в кабеле) | 1. оператив хәтер 2. төш 3. бакыр чыбык, тамыр, кабель тамыры |
| **corporate** | корпоративный, общий | корпоратив, гомуми |
| **correlator** | коррелятор | коррелятор |
| **count** | счёт | исәп; исәпләү |
| **counter** | счётчик | санагыч |
| **country** | страна | ил [исеме] |
| **country code** | код страны | ил коды |

| | | |
|---|---|---|
| **county** | округ | округ, төбәк |
| **course** | курс | курс |
| **coworker** | коллега | хезмәттәш |
| **CPU (Central Processor Unit)** | ЦП (центральный процессор) | ҮП (үзәк процессор) |
| **cracker** | взломщик [компьютерных систем] | рөхсәтсез керүче, [компьютер системаларына] рөхсәтсез үтеп керүче |
| **crash** | авария, сбой, аварийное завершение программы | авария, эштән чыгу, сафтан чыгу |
| **crawler** | поисковый агент, «паук», «червяк», «гусеница» | эзләү агенты, «үрмәкүч», «корт» (программа тур.) |
| **create** | создать | төзү, булдыру, эшләү |
| **creator** | разработчик | [программа] төзүче |
| **credentials** | учётные данные | таныклау мәгълүматы |
| **credit** | балл | балл |
| **credit card** | кредитная карта | кредит картасы |
| **criteria** | условия | шартлы чикләүләр, шартлар |
| **critical update** | критическое обновление | махсус яңарту |
| **crop** | обрезать | кисү, кисеп алу |

| | | |
|---|---|---|
| **cross hatch** | клетчатая штриховка | шакмаклап штрихлау |
| **cross-functional flowchart** | функциональная блок-схема | функциональ блок-схема |
| **crosshatching** | штриховка | штрихлау |
| **cross-platform** | межплатформный | платформаара |
| **cross-posting** | отправка в несколько адресов | берничә адреска җибәрү |
| **cross-reference** | перекрёстная ссылка | кисешкән сылтама |
| **crufty program** | неработоспособная программа | эшләми торган программа |
| **crying** | плач | елау |
| **cube** | куб | куб |
| **curfew** | запретное время | куллану тыелган вакыт, тыюлы куллану вакыты |
| **currency** | валюта, деньги | валюта, акча |
| **currency symbol** | обозначение денежной единицы | акча берәмлеге билгесе |
| **current task** | текущая задача | актив бирем, агымдагы бирем |
| **currently** | на данный момент | әлегә |
| **cursor** | курсор | курсор, күрсәр |

| | | |
|---|---|---|
| **cuspy program** | аккуратная программа, надёжная программа | ышанычлы программа (теләсә кайсы кулланучыда яхшы эшли торган) |
| **custom** | пользовательский, настраиваемый | кулланучы ...ы, кулланучы карамагындагы |
| **custom control** | пользовательский элемент управления, расширенный управляющий элемент | көйләүле идарә элементы, киңәйтелгән идарә элементы |
| **custom dictionary** | настраиваемый словарь | кулланучы сүзлеге |
| **custom group** | настраиваемая группа | көйләүле төркем |
| **custom install** | выборочная установка | сайлап урнаштыру |
| **custom installation** | *см.* **custom install** | |
| **custom toolbar** | настраиваемая панель инструментов | көйләнә торган кораллар панеле |
| **customize** | настроить, выбрать [параметры] | көйләү, [параметрларын] сайлау |
| **cut** | вырезать | кисеп алу |
| **cyberarts** | компьютерные произведения искусства | компьютер сәнгате |
| **cybermall** | электронный магазин | электрон кибет |
| **cybernetics** | кибернетика | кибернетика |

| | | |
|---|---|---|
| **cyberspace** | киберпространство | киберкиңлек |
| **cycle** | цикл | цикл |
| **cycle statement** | оператор цикла | цикл операторы |
| **cyclical shift** | циклический сдвиг | циклик күчеш |
| **cylinder (CYL)** | цилиндр | цилиндр |

D

| | | |
|---|---|---|
| **daily** | ежедневно | көн саен, һәр көн |
| **dance** | **I** *гл.* танцевать **II** *сущ.* танец | **I** *ф.* бию **II** *и.* бию |
| **dangling reference** | «повисшая» ссылка | «эленеп калган» сылтама |
| **DAO (1. Data Access Objects 2. Disk-at-once recording)** | DAO (1. интерфейс DAO (программный интерфейс Microsoft для доступа к данным) 2. способ копирования компакт-дисков в CD-R (диск копируется по секторам, а не по дорожкам)) | DAO (1. DAO интерфейсы (мәгълүмат базасына керү өчен Microsoft программа интерфейсы) 2. компакт дискларны CD-Rга күчереп яздыру ысулы (дисктагы мәгълүмат башка бер дискка юллап түгел, секторлап күчерелә)) |
| **dash** | штрих, тире | сызык |
| **data** | данные | мәгълүмат |
| **data administrator** | администратор данных | мәгълүмат администраторы |

| | | |
|---|---|---|
| **data attribute** | атрибут данных, описатель данных | мәгълүмат тасвирламасы, мәгълүмат атрибуты |
| **data bank** | банк данных | мәгълүмат банкы |
| **data bar** | гистограмма | гистограмма, мәгълүмат бага-насы |
| **data base (DB)** | база данных (БД) | мәгълүмат базасы (МБ) |
| **data base management system (DBMS)** | система управления базой данных (СУБД) | мәгълүмат базасы белән идарә итү системасы (МБИС) |
| **data buffer** | буфер данных | мәгълүмат буферы |
| **data connection file** | файл подключения к данным | мәгълүмат базасына тоташу файлы |
| **data consistensy** | непротиворечивость данных | мәгълүматның каршылыклы булмавы |
| **data control** | контроль данных | мәгълүмат контроле |
| **data conversion** | преобразование данных | мәгълүматны үзгәртү |
| **data deletion** | удаление данных | мәгълүматны бетерү, мәгълүматны сөртү |
| **data density** | плотность записи | язу тыгызлыгы; язма тыгызлыгы |
| **data element** | элемент данных | мәгълүмат элементы |
| **data entity** | объект данных | мәгълүмат объекты |

| | | |
|---|---|---|
| **data entry** | запись данных | мәгълүмат язу |
| **data entry staff** | персонал, занимающийся вводом информации | мәгълүмат кертүче персонал |
| **data error** | ошибка данных | мәгълүматтагы хата |
| **data extraction** | извлечение данных | мәгълүмат алу |
| **data field** | поле данных | мәгълүмат кыры |
| **data filter** | информационный фильтр | мәгълүмат фильтры |
| **data flow** | поток данных | мәгълүмат агымы |
| **data form** | форма данных | мәгълүмат формасы |
| **data format** | формат данных | мәгълүмат форматы |
| **data formatting** | форматирование данных | мәгълүматны форматлау |
| **data graphic** | рисунок, связанный с данными | мәгълүмат графигы |
| **data hiding** | ограничение доступа к данным | мәгълүмат базасына керүне чикләү, мәгълүмат алуны чикләү, мәгълүматны яшерү |
| **data hierarchy** | иерархия данных | мәгълүмат иерархиясе |
| **data integrity** | целостность данных | мәгълүмат бөтенлеге |
| **data item** | элемент данных; элементарное данное | мәгълүмат элементы; элементар мәгълүмат берәмлеге |

| | | |
|---|---|---|
| **data label** | метка данных | мәгълүмат тамгасы |
| **data mining** | извлечение информации [из данных], добыча данных | мәгълүмат табу, табып алу, юнәтү |
| **data model** | модель данных | мәгълүмат моделе |
| **data network** | сеть передачи данных | мәгълүмат тапшыру челтәре |
| **data output** | вывод данных | мәгълүматны чыгару |
| **data point** | точка данных | мәгълүмат ноктасы |
| **data preparation** | подготовка данных | мәгълүмат әзерләү |
| **data processing** | обработка данных | мәгълүмат эшкәртү |
| **data protection** | защита данных | мәгълүматны саклау |
| **data record** | запись данных | мәгълүмат язуы, язмасы |
| **data representation** | представление данных | мәгълүмат күрсәтелеше, мәгълүмат күрсәтелү рәвеше |
| **data retrieval** | поиск данных | мәгълүмат эзләп табу |
| **data scan** | сканирование [трактов] данных | мәгълүмат [трактларын] сканер-лау |
| **data search** | поиск данных | мәгълүмат эзләү |
| **data security** | защита [безопасность] данных | мәгълүмат иминлеге |
| **data segment** | сегмент данных | мәгълүмат сегменты |

| | | |
|---|---|---|
| **data series** | ряд данных | мәгълүмат рәте |
| **data set** | набор данных | мәгълүмат җыелмасы |
| **data sharing** | совместное использование данных | мәгълүмат уртаклашу, мәгълүматтан уртак файдалану |
| **data source** | источник данных | мәгълүмат чыганагы |
| **data store** | склад данных | мәгълүмат саклагыч |
| **data stream** | поток данных | мәгълүмат агымы |
| **data stream** | *см.* **media stream** | |
| **data structure** | структура данных | мәгълүмат структурасы |
| **data table** | таблица данных | мәгълүмат таблицасы |
| **data transfer** | передача (пересылка) данных | мәгълүмат күчерү |
| **data transformation** | преобразование данных | мәгълүматны үзгәртү |
| **data transmission** | пересылка (передача) данных | мәгълүмат тапшыру |
| **data type** | тип данных | мәгълүмат төре |
| **data validation** | проверка данных | мәгълүматны тикшерү |
| **database** | база данных | мәгълүмат базасы |

| | | |
|---|---|---|
| **database administrator** | администратор базы данных | мәгълүмат базасы администра-торы |
| **database application** | СУБД-приложение | МБИС кушымтасы |
| **database connection** | подключение к базе данных | мәгълүмат базасына тоташу |
| **database design** | структура БД | МБ структурасы |
| **database event** | событие БД | МБ вакыйгасы |
| **database integrity** | целостность БД | МБ бөтенлеге |
| **database management system (DBMS)** | система управления базой данных (СУБД) | мәгълүмат базасы белән идарә итү системасы, МБИС |
| **database manager** | система управления базой данных (СУБД) | мәгълүмат базасы белән идарә итү системасы, МБИС |
| **database server** | сервер баз данных, сервер БД | мәгълүмат базасы серверы, МБ серверы |
| **database structure** | структура базы данных | мәгълүмат базасы структурасы |
| **datasheet** | таблица | мәгълүмат таблицасы |
| **dawn** | рассвет | кояш чыгу |
| **day** | день | көн |

| | | |
|---|---|---|
| **deactivate** | выключить | сүндереп кую, өзү |
| **debug** | **I** *сущ.* отладка **II** *гл.* отладить | **I** *и.* хата табу, көйләү **II** *ф.* көйләү, төзәтү |
| **debugger** | программа-отладчик | көйләү программасы |
| **Dec** | *см.* **December** | |
| **December** | декабрь | декабрь |
| **decision support system (DSS)** | система поддержки принятия решения | карар тәэминаты, карар кабул итү тәэминаты |
| **decision support tools** | средства поддержки принятия решений | карар тәэминаты, карар кабул итү чаралары |
| **declarative language** | декларативный язык | декларатив тел |
| **declare** | объявить, описать | белдерү, сурәтләү, тасвирлау |
| **decline** | отклонить | баш тарту, кабул итмәү, кире кагу |
| **decode** | декодировать, расшифровать | кодын чишү, шифрын ачу |
| **decoder** | дешифратор, декодер | дешифратор, декодер |
| **decompiler** | декомпилятор | декомпилятор |
| **decompiling** | декомпиляция | декомпиляция |
| **decomposition** | декомпозиция | декомпозиция |

| | | |
|---|---|---|
| **decrement** | уменьшить | киметү |
| **decrypt** | расшифровать | шифрын ачу |
| **decryption** | расшифровка | шифрын ачу |
| **default** | по умолчанию | килешенгән, килешенгәнчә, килешү нигезендә |
| **default button** | кнопка, используемая по умолчанию | стандарт төймә, килешенгән төймә |
| **default drive** | дисковод [выбираемый] по умолчанию | килешенгән дискйөрткеч |
| **default font** | шрифт по умолчанию | килешенгән шрифт (башкалары тәгаенләнмәгән очракта кулланыла торган гадәти гарнитуралы һәм зурлыктагы шрифт) |
| **default option** | выбор по умолчанию | килешенгәнчә сайлау |
| **default route** | маршрут по умолчанию | килешенгән маршрут |
| **default server** | сервер по умолчанию, текущий сервер | килешенгән сервер, гамәлдәге сервер |
| **default setting** | настройка по умолчанию | төп көйләнеш |
| **default value** | значение по умолчанию | килешенгән кыйммәт, стандарт зурлык, стандарт мәгънә бирәмлеге |

| | | |
|---|---|---|
| **defined name** | определённое имя | [аерым бер объектка] тәгаенләнгән исем |
| **defragmentation** | дефрагментация | дефрагментлау, [мәгълүматны] бер урынга туплау |
| **degree** | градус | градус |
| **delay** | задержка | тоткарлык |
| **delegate** | **I** *сущ.* делегат, представитель **II** *гл.* делегировать, передать полномочия [функции] | **I** *и.* делегат, вәкил **II** *ф.* вәкил итеп җибәрү, вәкаләт тапшыру |
| **delete** | удалить, уничтожить, стереть | бетерү, юк итү, сызып ату |
| **DELETE key** | клавиша DELETE | DELETE төймәсе |
| **deleted** | удалено | бетерелгән |
| **delimiter** | разделитель | аергыч |
| **deliver** | доставить | ирештерү, китереп җиткерү, тапшыру |
| **delivered** | доставлено | тапшырылды |
| **demon** | демон | демон, яшерен агент (башка процесс барышында фон режимында үтәлә торган операция) |

| | | |
|---|---|---|
| **demote** | понизить | дәрәҗәсен төшерү |
| **density** | плотность, интенсивность | тыгызлык, интенсивлык |
| **deny** | 1. отрицать 2. отказаться, отклонить | 1. инкяр итү 2. баш тарту, кабул итмәү, кире кагу |
| **department** | отдел | бүлек |
| **dependents** | зависимый объект | бәйле объект, буйсынулы бәйләнештәге объект |
| **deploy** | развернуть | кулланышка кертү |
| **depth of field** | глубина резкости | ачыклык дәрәҗәсе |
| **descending** | по убыванию | кимү буенча |
| **descending sort** | сортировка по убыванию | кимүгә таба сортлау |
| **description** | описание | тасвирлама |
| **descriptor** | 1. дескриптор, описатель 2. паспорт, ключевое слово, идентификатор | 1. дескриптор, сурәтләгеч 2. паспорт, ачкыч сүз, төп сүз, идентификатор |
| **deselect** | снять выделение | аерып күрсәтүне бетерү |
| **design element** | элемент оформления, элемент проекта | бизәү элементы |
| **design template** | шаблон оформления | бизәү үрнәге |

| | | |
|---|---|---|
| **design view** | конструктор (окно) | конструктор режимы, конструктор тәрәзәсе |
| **desktop** | «рабочий стол», экранная среда | [экрандагы] «эш өстәле» |
| **desktop apps** | приложения для ПК, офисные приложения | шәхси компьютер кушымталары, офис кушымталары |
| **desktop computer** | настольный ПК | өстәл компьютеры |
| **desktop gadget** | гаджет рабочего стола | эш өстәле гаджеты, эш өстәленә чыгарылган җайланма [сурәте] |
| **desktop pattern** | рисунок фона | экран рәсеме, фон рәсеме |
| **desktop publishing system** | настольная редакционно-издательская система | җыйнак редакцияләү-бастыру системасы |
| **destination** | место назначения | саклау урыны, күчерү урыны |
| **destination file** | конечный файл | тәгаенләнгән файл |
| **detach** | отделить; разъединить | аерып кую (урнаштырылмаган кушымта файлларын тәгаенләнгән компьютердан алу, бетерү) |
| **detached process** | фоновый процесс | фондагы процесс; икенчел процесс |
| **detail** | деталь, подробность, свойство | деталь, үзенчәлек, нечкәлек |

| | | |
|---|---|---|
| **details** | подробности, информация | тулырак мәгълүмат |
| **developer** | разработчик [программ] | [программа] төзүче |
| **development** | разработка | булдыру, төзү, ясау |
| **device** | устройство | җайланма |
| **device access** | обращение к внешнему устройству | тышкы җайланмага мөрәҗәгать [итү] |
| **device driver** | драйвер устройства | җайланма драйверы |
| **dial** | набрать номер | [телефонда] номер җыю, шалтырату |
| **dial tone** | гудок | гудок |
| **dialer** | набиратель номера | номер җыйгыч (үзлегеннән телефон номерын җыеп, компьютер системасына зарар китерү ихтималы булган программа тур.) |
| **dialing** | набор номера | номер җыю |
| **dialler** | наборщик номера | номер җыйгыч |
| **dialog** | диалог | диалог |
| **dialog box** | диалоговое окно | элемтә тәрәзәсе, өстәмә мәгълүмат тәрәзәсе |
| **dialog mode** | диалоговый режим, интерактивный режим | диалог режимы, интерактив режим |

| | | |
|---|---|---|
| **dialog system** | диалоговая система | диалог системасы |
| **dialog window** | диалоговое окно | диалог тәрәзәсе |
| **dialpad** | клавиатура набора номера | төймәләр |
| **dial-up access** | доступ по [коммутируемой] телефонной линии | [номер җыеп] тоташу мөмкинлеге (телефон аша тоташу) |
| **dial-up connection** | [коммутируемое] соединение по телефонной линии | [номер җыеп] тоташу (телефон аша тоташу) |
| **dictation software** | программа речевого ввода текста | сөйләмне яздыру (кертү) программасы |
| **dictation system** | система речевого ввода текста (с голоса) | сөйләмне яздыру (кертү) системасы |
| **dictionary** | словарь | сүзлек |
| **dictionary attack** | восстановление пароля по словарю | серсүзне сүзлектән тергезү, серсүзне сүзлек ярдәмендә тергезү |
| **digital** | цифровой | цифрлы, цифрлы форматтагы |
| **digital camera** | цифровая [фото]камера | цифрлы [фото]камера |
| **digital cash** | электронные деньги | электрон акча |
| **digital certificate** | цифровой сертификат | цифрлы сертификат |
| **digital computer** | цифровая вычислительная машина (ЦВМ) | цифрлы исәпләү машинасы (ЦИМ) |

| | | |
|---|---|---|
| **digital device** | цифровое устройство | цифрлы җайланма |
| **digital image** | цифровое изображение | цифрлы сурәт |
| **digital ink** | рукописный ввод, рукописный фрагмент | цифрлы кульязма |
| **digital license** | цифровая лицензия | цифрлы лицензия, цифрлы рөхсәтнамә, цифрлы рөхсәт язуы |
| **digital money** | цифровые деньги | цифрлы акча |
| **digital photo** | цифровая фотография | цифрлы фото |
| **digital photography** | *см.* **digital photo** | |
| **digital signal** | цифровой сигнал, дискретный сигнал | цифрлы сигнал, дискрет сигнал |
| **digital signature** | цифровая подпись | цифрлы имза |
| **digital video** | цифровое видео | цифрлы видео |
| **digital video disk** | DVD-диск | DVD диск |
| **digitalization** | оцифрование | цифрлаштыру, мәгълүматны цифрлы форматка күчерү |
| **digitally sign** | ставить цифровую подпись | цифрлы имза кую |
| **digitiser** | дигитайзер | дигитайзер, цифрлаштыргыч, цифрлаштыру җайланмасы |

| | | |
|---|---|---|
| **dim** | **I** *сущ.* экономичный режим **II** *гл.* уменьшить яркость | **I** *и.* экономияле режим, тонык режим **II** *ф.* тонықландыру, яктылыгын киметү |
| **dimension** | аналитика, измерение | үлчәм |
| **dimension level** | уровень измерения | үлчәм дәрәҗәсе |
| **direct access** | 1. прямой доступ 2. случайный доступ | 1. турыдан-туры эш, турыдан-туры керү 2. очраклы рәвештә керү, ялгыш керү |
| **direct access memory** | память с прямым доступом | турыдан-туры кереп булган хәтер |
| **direct connection** | прямое подсоединение, соединение по выделенной линии | турыдан-туры тоташу |
| **direct memory access** | прямой доступ к памяти | хәтергә турыдан-туры керү |
| **directive** | директива | директива |
| **directory** | каталог | каталог |
| **directory control block** | блок управления каталогами | каталоглар белән идарә итү блогы |
| **directory tree** | дерево каталогов | каталоглар агачы |

| | | |
|---|---|---|
| **disable** | отключить | өзү, сүндерү |
| **disabled** | отключённый | өзелгән, сүндерелгән |
| **disabled control** | отключённый элемент управления | өзелгән идарә элементы |
| **disagree** | не принять, не согласиться | килешмәү, кабул итмәү |
| **disc** | диск | диск |
| **disc drive** | дисковод | дискйөрткеч |
| **discard** | отвергнуть, отклонить, отказаться | кире кагу |
| **discard changes** | отменить изменения | үзгәрешләрне кабул итмәү, үзгәрешләрдән баш тарту |
| **discharging** | разрядка | бушау, коруы бетү |
| **disclaimer** | отказ [от ответственности] | [җаваплылыктан] баш тарту |
| **disconnect** | отключить | өзү, сүндерү |
| **disconnected** | отключённый | өзелгән, сүндерелгән |
| **discoverable** | поддающийся обнаружению, видимый | эзләп табарлык, күренә торган |
| **discussion group** | группа обсуждений | фикер алышу төркеме |

| | | |
|---|---|---|
| **disjunction** | дизъюнкция | дизъюнкция |
| **disk** | диск | диск |
| **disk array** | дисковый массив, матричная дисковая подсистема | диск массивы, матрицалы диск ассистемасы |
| **disk compressing** | сжатие диска, уплотнение диска | дискны кысу, дискны тыгызлау |
| **disk drive** | дисковод | дискйөрткеч |
| **disk error** | ошибка диска | диск хатасы |
| **disk format** | формат диска; формат записи; разметка диска | диск форматы, язма форматы |
| **disk initialization** | форматирование диска, форматирование | дискны форматлау, форматлау |
| **disk operating system (DOS)** | дисковая операционная система (ДОС) | дисклы операцион система (ДОС) |
| **disk partition** | раздел диска | диск сегменты, диск өлеше |
| **disk sector** | сектор диска, сектор | диск секторы, сектор |
| **disk storage** | дисковая память; дисковое запоминающее устройство | диск хәтере, дискта саклау җайланмасы |
| **dismiss** | отменить | бетерү (команда һ. б. ш.) |

| | | |
|---|---|---|
| **display** | **I** *гл.* высветить, отобразить, вывести [на экран] **II** *сущ.* дисплей, монитор | **I** *ф.* күрсәтү, [экранга] чыгару **II** *и.* дисплей, монитор, күрәк |
| **display adapter** | видеоадаптер, видеокарта | видеоадаптер, видеокарта |
| **display name** | отображаемое имя | күрсәтелгән исем |
| **display picture** | картинка | күрсәтелгән рәсем |
| **distributed** | распределённый | таратылган; бүлгәләнгән, төрле урында урнашкан |
| **distributed database** | распределённая база данных | берничә урында урнашкан мәгълүмат базасы |
| **distributed processing** | распределённая обработка | бүлгәләп эшкәртү |
| **distribution** | распространение, дистрибуция, поставка, внедрение; распределение | тарату, тәэмин итү, дистрибуция; бүлү |
| **distribution group** | группа рассылки | күмәк адресат, күмәк адресат төркеме |
| **distribution kit** | дистрибутивный комплект | дистрибутив комплект |
| **distribution list** | список рассылки | тарату исемлеге |
| **district** | округ | төбәк |

| | | |
|---|---|---|
| **dither** | размывание [контура изображения], сглаживание цветовых переходов | төстән төскә күчешләрне шомарту |
| **do** | сделать, выполнить | эшләү, башкару, үтәү |
| **doc** | *см.* **document** | |
| **dock** | закрепить | беркетү |
| **docked toolbar** | закреплённая панель | беркетелгән панель, беркетмә панель |
| **docking** | установка в порт | портка кую |
| **document** | документ | документ |
| **document database** | документная база данных | документлар базасы |
| **document element** | элемент документа | документ элементы |
| **document profile** | профиль (дескриптор) документа; резюме, аннотация | документ профиле; резюме, йомгак, аннотация (автоматлаштырылган идарә системасында) |
| **document properties** | свойства документа | документ үзлекләре |
| **document type definition** | определение типа документа (ОТД) | документ тибын билгеләү |

| | | |
|---|---|---|
| **document window** | окно документа | документ тәрәзәсе |
| **documentation** | документация | документация; документлаштыру |
| **domain** | домен | домен |
| **domain controller** | контроллер домена | домен контроллеры |
| **done** | сделанный, выполненный | эшләнгән, башкарылган, үтәлгән |
| **dot** | **I** *сущ.* 1. точка 2. десятичная точка **II** *гл.* ставить точки, помечать пунктиром | **I** *и.* 1. нокта, төртке 2. унлы нокта **II** *ф.* ноктalар кую, пунктирлау |
| **dot matrix** | точечная матрица, растр | нокталы матрица, растр |
| **dot matrix plotter** | матричный графопостроитель | матрицалы плоттер |
| **dot matrix printer** | матричное печатающее устройство, матричный принтер | матрицалы принтер, матрицалы бастыру җайланмасы |
| **dot pitch** | размер точки, шаг триад в мониторах | нокта зурлыгы, мониторлардагы триадалар арасы (атламы) |
| **dots per inch** | ... точек на дюйм | нокта/дюйм |
| **dotted** | пунктирный | пунктирлы, нокталы |
| **double density (DD)** | двойная плотность | икеләтә тыгызлык |

| | | |
|---|---|---|
| **double precision** | удвоенная точность, двойная точность | икеләтә төгәллек |
| **double sided (DS)** | двусторонний | ике яклы |
| **double-click** | дважды щёлкнуть | ике тапкыр чиртү |
| **download** | **I** *гл.* загрузить, скачать **II** *сущ.* загрузка | **I** *ф.* күчереп алу, яздырып алу, йөкләү **II** *и.* күчереп алынган материал, мәгълүмат (документ, файл һ. б. ш. тур.) |
| **downloadable font** | загружаемый шрифт | йөкләнә торган шрифт |
| **downloaded** | загруженный | күчереп алынган, күчерелгән |
| **downloading** | загрузка | күчереп алу |
| **dpi** | *см.* **dots per inch** | |
| **DPI scaling** | масштабирование | масштаблау |
| **draft** | **I** *сущ.* проект, набросок, черновик **II** *гл.* набросать черновик, составить план | **I** *и.* проект, каралама **II** *ф.* планын төзү, караламада әзерләү |
| **draft** | черновик | каралама |
| **draft mode** | черновая печать | каралама басма |
| **drafts folder** | черновая папка | караламалар папкасы |

| | | |
|---|---|---|
| **drag** | перетащить | тартып күчерү, шудырып күчерү |
| **drag-and-drop** | перетаскивание | тартып күчерү, шудырып күчерү |
| **drawing** | рисование, черчение | рәсем ясау, сызым сызу |
| **drive** | дисковод | дискйөрткеч |
| **drive letter** | буква диска | диск хәрефе |
| **driver** | драйвер | драйвер |
| **driving** | на автомобиле | машинада |
| **drop** | 1. падать, опуститься; вывалиться 2. распустить 3. делать петлю | 1. коелу, төшү; ишелү; салыну 2. ачу 3. элмәк ясау |
| **drop cable** | ответвительный кабель; отвод | тармаклы кабель; кабель тармагы |
| **drop line** | линия проекции | проекция сызыгы |
| **drop-down combo box** | поле с раскрывающимся списком | ачыла торган исемлек күзе |
| **drop-down list** | раскрывающийся список | ачыла торган исемлек |
| **drop-down menu** | раскрывающееся меню | ачыла торган меню |
| **drum** | **I** *сущ.* барабан, полый цилиндр **II** *прил.* барабанный | **I** *и.* барабан, эче буш цилиндр **II** *с.* барабан ...ы, барабанлы |

| | | |
|---|---|---|
| **drum plotter** | барабанный графопострои-тель | барабанлы плоттер |
| **drum scanner** | барабанный сканер | барабанлы сканер |
| **dual boot** | двухвариантная загрузка, с альтернативной загрузкой | төрлечә йөкләнү, ике төрле йөкләнү |
| **due date** | дата выполнения | үтәлү датасы |
| **duplex** | **I** *прил.* двойной, двусторонний, спаренный; **II** *сущ. см.* **duplex transmission** | **I** *с.* икеле, ике яклы, парлы **II** *и. к.* **duplex transmission** |
| **duplex printer** | принтер с двусторонней печатью [страниц] | [битләргә] ике яклап бастыру принтеры |
| **duplex printing** | двусторонняя печать | ике яклы бастыру, ике яклап бастыру |
| **duplex transmission** | дуплексная передача | дуплекслы тапшыру (ике станция арасында мәгълүмат тапшыру берьюлы ике якка да бара торган бәйләнеш режимы) |
| **duration** | продолжительность | озынлык, дәвамлылык |
| **dynamic** | динамический | динамик |
| **dynamic Web page** | динамическая Web-страница | динамик веб бит |

# E

| | | |
|---|---|---|
| **east** | восток | көнчыгыш |
| **eBay** | eBay | eBay |
| **echo** | эхо | кайтаваз |
| **echo cancellation** | эхоподавление | кайтавазны басу |
| **edge** | **I** *сущ.* 1. дуга, ребро, сторона плоского объекта 2. граница, контур, край **II** *гл.* обрезать края | **I** *и.* 1. дуга, кабырга, яссы объектның ягы 2. чик, контур, кырый **II** *ф.* кырыен кисү, читен кисү |
| **edit** | **I** *сущ.* редактирование **II** *гл.* изменить, исправить | **I** *ф.* редакцияләү **II** *ф.* үзгәртү, төзәтү |
| **edit keys** | клавиши редактирования | редакцияләү төймәләре |
| **edit line** | строка редактирования | редакцияләү юлы |
| **edit mode** | режим редактирования | редакцияләү режимы |
| **editing** | редактирование | редакцияләү, төзәтү |
| **editor** | редактор | редактор |
| **edutainment** | обучение с элементами развлечения | мавыктырып өйрәтү |
| **effect** | эффект | эффект |

| | | |
|---|---|---|
| **effective** | эффективный | эффектив, нәтиҗәле |
| **effector** | эффектор | эффектор |
| **eject** | извлечь, вытолкнуть, разгрузить | чыгарту, чыгару, бушату |
| **electronic circuit** | электронная схема | электрон схема |
| **electronic disk** | электронный диск, виртуальный диск | электрон диск, виртуаль диск |
| **electronic document** | электронный документ | электрон документ |
| **electronic mail** | электронная почта | электрон почта |
| **element** | элемент | элемент |
| **ellipsis** | многоточие | күпнокта |
| **em dash** | длинное тире | озын тире |
| **email** | **I** *сущ.* электронная почта 2. электронное письмо **II** *гл.* отправить по электронной почте | **I** *и.* 1. электрон почта 2. электрон хат **II** *ф.* электрон почта аша җибәрү |
| **e-mail** | *см.* **email** | |
| **e-mail account** | учётная запись электронной почты | электрон почта теркәү мәгълүматы |
| **email address** | адрес электронной почты | электрон почта адресы |

| | | |
|---|---|---|
| **e-mail address** | *см.* **email address** | |
| **email box** | почтовый ящик | почта тартмасы |
| **e-mail flooder** | троян рассылки почты | почта тарату трояны (зарарлы программа) |
| **e-mail message** | сообщение электронной почты | электрон почта хаты |
| **e-mail server** | почтовый сервер | электрон почта серверы |
| **embarrassed** | смущённый, растерянный | оялган, каушаган |
| **embed** | внедрить | кертеп беркету |
| **embedded audio clip** | внедрённый аудиоклип | кертеп беркетелгән аудиоклип |
| **embedded object** | внедрённый объект | кертеп беркетелгән объект |
| **embedded video clip** | внедрённый видеоклип | кертеп беркетелгән видеоклип |
| **emboss** | сделать рельеф | рельеф ясау, рельефлау |
| **emoticon** | смайлик | смайлик, эмотикон |
| **emoticons** | смайлы | чырайлар, смайллар |
| **empty** | пустой, незанятый, незаполненный | буш, тутырылмаган |
| **empty list** | пустой список | буш исемлек |

| | | |
|---|---|---|
| **empty loop** | пустой цикл | буш цикл |
| **empty set** | пустое множество | буш күплек |
| **empty string** | пустая строка, строка нулевой длины | буш юл |
| **emulation** | эмуляция | эмуляция (компьютерның бер төре өчен төзелгән программаны икенчесенә урнаштырып эшләтү) |
| **emulator** | эмулятор | эмулятор (компьютерның бер төре өчен төзелгән программаны икенчесенә урнаштырып эшләтү чарасы, ягъни программа, микропрограмма һ. б. ш.) |
| **en dash** | короткое тире | кыска тире |
| **enable** | включить; разрешить | тоташтыру, кабызу |
| **encoding** | кодирование | кодлау, кодка салу |
| **encrypt** | шифровать | шифрлау |
| **encryption** | шифрование | шифрлау |
| **encryption key** | ключ шифрования | шифрлау ачкычы |
| **end** | завершить | тәмамлау |
| **end user** | пользователь | кулланучы |

| | | |
|---|---|---|
| **English** | I *прил.* английский II *сущ.* английский язык | I *с.* инглиз ...ы, инглизчә II *и.* инглиз теле, инглизчә |
| **enhanced** | улучшенный | камилләштерелгән |
| **enhanced audio CD** | усовершенствованный звуковой компакт-диск | камилләштерелгән аудио- компакт диск |
| **enhanced DVD movie** | усовершенствованный видео-DVD-диск | камилләштерелгән видео- DVD диск |
| **enqueue** | ставить в очередь | чиратка кую |
| **enter** | 1. войти 2. внести, ввести | 1. керү 2. кертү |
| **ENTER key** | клавиша ВВОД | ENTER төймәсе |
| **entity** | *см.* **external content type** | |
| **environment** | среда, окружение | мохит, тирәлек (программалар, җайланмалар һ. б. ш. гомуми торышын билгеләүче) |
| **epilogue code** | код выхода | чыгу коды (мәс., процедурадан) |
| **equal sign** | знак равенства | тигезлек билгесе |
| **equaliser** | эквалайзер | эквалайзер |
| **equation** | уравнение | тигезләмә |
| **equation editor** | редактор [математических] формул и уравнений | [математик] формулалар һәм тигезләмәләр редакторы |

| | | |
|---|---|---|
| **equipping** | ввод в [рабочую] конфигурацию, подготовка к работе | эшкә әзерләү, конфигурациягә кертү |
| **erasable** | стираемый | сөртелә торган (мәс., хәтер) |
| **erase** | **I** *сущ.* стирание **II** *гл.* стереть, удалить, уничтожить | **I** *и.* сөртү **II** *ф.* сөртү, бетерү, юк итү (мәс., дисктагы файлларны) |
| **erase head** | стирающая головка, головка стирания | сөртүче эшләпә |
| **eraser** | 1. инструмент «ластик» 2. стирающее устройство | 1. «бозгыч» 2. сөртү җайланмасы |
| **error** | ошибка | хата |
| **error code** | код ошибки | хата коды |
| **error handler** | обработчик ошибок | хата эшкәрткеч |
| **error log** | журнал ошибок | хаталар журналы |
| **error message** | сообщение об ошибке | хата хәбәре, хата турында хәбәр |
| **error rate** | частота [появления] ошибок | хаталар ешлыгы |
| **escape** | **I** *сущ.* 1. переход 2. выход **II** *гл.* выйти, отменить, отключить | **I** *и.* 1. күчү 2. [программадан] чыгу **II** *ф.* чыгу, баш тарту, элемтәне өзү, тоташтыруны өзү |
| **evaluate** | оценить | бәяләү |
| **evaluate** | вычислить | исәпләү |

| | | |
|---|---|---|
| **event** | 1. событие 2. происшествие | 1. вакыйга (системада берәр гамәлнең башкарылуы, мәс., төймәгә басу, тычкан-ны хәрәкәтләндерү) 2. очрак (челтәрдә, системада яки кушымталарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәл) |
| **event address** | адрес события | вакыйга адресы |
| **event handler** | обработчик событий | вакыйга эшкәрткече |
| **everyone** | каждый, все | һәркем |
| **exact** | точный, строгий | төгәл |
